# Ватан иминлеге ышанычлы кулларда

## *Махсус хәрби операциядә катнашучы укучыбыз һәм әтиләребез*

### Билалов Илгизәр Илдус улы




1980 елда Минзәлә районы Боерган авылында туа. 1987-1997 елларда Боерган урта мәктәбендә белем ала.

1999-2001 елларда армия сафларында хезмәт итә. 2001 елдан - Түбән Кама шәһәрендә “Нефтехим” предприятиесендә, 2004 елдан Чаллыда ”Челны-лес” та һәм “Стройдеталь” дә склад мөдире булып хезмәт куя. 2016 елдан “ Татпрофиль”дә эшли. 2022 елның 29 сентябрендә махсус хәрби операциягә мобилизацияләнә. Луганск халык республикасында хезмәт итә. Батырлыгы өчен 2022 елда “За воинскую доблесть” медале белән бүләкләнә.



**Билалов Илгизәр Илдус улы – 5В сыйныфы укучысы Айзат**
**һәм 8В сыйныфы укучысы Азамат Билаловларның әтисе**

**Зиннәтуллин Наил Нурулла улы**



1987 елның 24 январенда Чаллы шәһәрендә туа. Балачагы Тукай районы Иске Дөреш авы-лында үтә. Башлангыч мәктәпне авылда тәмамлагач, Чаллыда 47 нче санлы урта мәктәптә белем ала. Белгечлеге буенча - юрист. 2018 елдан КамАЗ заводында эшли. 2022 елның но-ябрь аенда “ Алга” батальонына махсус хәрби операциягә чакырыла.

**Зиннәтуллин Наил Нурулла улы –**
**4А сыйныфы укучысы Зиннәтуллина Гүзәлнең әтисе**

**Хамзин Ирек Вәлиҗан улы**





1981 елның октябрендә Аксубай районы Иске Ибрай авылында туа. Чаллы шәһәренең 52 нче санлы мәктәбендә белем ала. 1999 -2001 елларда чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. 2002-2005 елларда Чаллы шәһәрендә ППС та кинолог булып эшли, 2005-2009 елларда ОМОН сафларында кинолог-сапер булып хезмәт итә. 2008 елда Чечня сугышында катнаша, күп медальләр һәм “Верность долгу” Кресты белән бүләкләнә. 2022 елның 26 октябрендә махсус хәрби операциягә мобилизацияләнә. Отделение командиры булып хезмәт итә. 2023 елның 1мартында яралана, контузия ала. Госпитальдә дәвалангач, кабат Украинада махсус хәрби операциядә. Дәүләт бүләкләренә ия.







**Хамзин Ирек Вәлиҗан улы – 11Б сыйныфы укучысы Галиуллин Илнурның әтисе**




**Салахов Илшат Фәргать улы**

1980 елның 1 гыйнварында Яңа Чишмә районы Чаллы Башы авылында туа. Әтисе Фәргать - машина йөртүче, әнисе Фидания балалар бакчасында пешекче булып эшли. Илшат 1987-1997 елларда Чаллы Башы урта мәктәбендә белем ала.1997 елда Әлмәт физкультура техникумына укырга керә. Техникумны уңышлы тәмамлагач, армия сафларына алына. Хәрби хезмәттән соң 2000 елда Чаллы шәһәрендә ОМОН да эшли башлый. 2012 елда Чечняда хезмәт итә.

Авыл кызы Альбина белән семья коралар. Гаиләдә тәрбияле ике кыз үстерәләр.

2022 елда махсус хәрби операциягә мобилизацияләнә. Хәзерге вакытта Украинада.

**Салахов Илшат Фәргать улы – 7В сыйныфы укучысы Ильвина һәм 2022-2023 уку елында 11Б сыйныфын тәмамлаган Гөлшат Салаховаларның әтисе.**

**Шәрәфиев Илнар Рәсим улы**







1994 елның 17 мартында Чаллы шәһәрендә Рәсим һәм Гүзәл Шәрәфиевлар гаиләсендә туа. 2001 елда М. Вахитов исемендәге 2 гимназиягә укырга керә. Класс җитәкчеләре – башлангыч класста Гарифуллина Вәрия Ганиевна, 5-9 класста Шәмсиева Әлфия Әхияровна. Гимназиядә яхшы укый, тәрбиялелеге, ярдәмчел булуы белән башкаларга үрнәк булып тора.

IX сыйныфны тәмамлагач, 2010 елда Чаллы Кама гуманитар-техник колледжына укырна керә, анда программист белгечлеге ала.

2014-2015 елларда Мәскәү шәһәре янында армиядә хезмәт итә. Армиядән кайткач, “Татпроф” предприятиесендә оператор булып эшли.

2022 елның 29 сентябрендә махсус хәрби операциягә Луганск шәһәренә мобилизацияләнә.

**Шәрәфиев Илнар Рәсим улы - 2 нче гимназия укучысы**